РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Краснокадкинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кызыл Чапчак авыл җирлеге
Советы

423558, Нижнекамский район,
с. Верхние Челны, ул. Молодежная, 13

423558, Түбән Кама районы,
Югары Чаллы авылы, Яшьләр урамы, 13

тел./факс (8555) 44-50-21, электронный адрес: Krasnokadkin.sp@tatar.ru, сайт: www.krasnokadkinskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

22.06.2021 ел № 10

Ышаныч югалу сәбәпле,
IV чакырылыш Кызыл Чапчак
авыл җирлеге депутаты
А.Р. Камалиеваның вәкаләтләрен
вакытыннан алда туктату турында

Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 27 маендагы 01-4810 номерлы гаризасын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.3, 7.3-1 өлешләренә, «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясына таянып, Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советы карар бирә

1. 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр турында белә торып дөрес һәм тулы булмаган белешмәләр, шулай ук 2020 елның 1 августына гамәлдә булган милек, кертемнәр, кыйммәтле кәгазьләр турында, мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыруда чагылдырылган «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4 өлешендә каралган вазыйфаларны үтәмәгән өчен, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советы депутаты Камалиева Алсу Рафис кызының вәкаләтләрен, ышаныч югалу сәбәпле, вакытыннан алда туктатырга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының персонал белән идарә итү һәм кадрлар сәясәте бүлеге җитәкчесе М.В. Ворошиловага, ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына мәгълүматларны кертү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вәкаләтле бүлекчәсенә мәгълүмат җибәрергә.

3. Әлеге карарга Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә аңа карата карар кабул ителгән зат тарафыннан шикаять бирелергә мөмкин.

Б.В.Илдарханов